Республика Татарстан
Глава
Ильбяковского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Илбәк авыл җирлеге
башлыгы

ул. А.Валеева, д. 53, село Ильбяково,
Азнакаевский район, 423321

Ә.Вәлиев урамы, 53нче йорт, Илбәк авылы,
Азнакай районы, 423321

Тел. (факс) 8(85592) 38-5-38; e-mail: Ilb.Azn@tatar.ru;
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» октябрь 2020 ел №3

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Тырыш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Уставы нигезендә, **карар чыгарам:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Тырыш торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены 2020 елның 31 октябренә билгеләргә.

1.2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Тырыш торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 2020 елның 31 октябре 14.00 сәг тән 15.00 сәг кә кадәр;

- үткәрү урыны – Тырыш бистәсе, Октябрьнең 70 еллыгы урамындагы 1нче йорт яны торриториясе дип билгеләргә.

1.3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2020 елның 21 октябреннән дә соңга калмыйча гражданнарга Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 50 йорт адрес буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитетында һәм Тырыш бистәсе, Октябрьнең 70 еллыгы урамындагы 1нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын бирергә;

- Тырыш торак пунктында сайлау хокукына ия булган яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән Тырыш торак пункты халкына гражданнарның җыены турында хәбәр итәргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез 2021 елда 1төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, Илбәк авыл җирлеге Тырыш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкән пенсионерлардан, күп балалы гаиләләрдән бер тапкыр түләтүне 150 сумга киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Тырыш бистәсенең җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (вак таш түшәмәле юллар төзү, вак ташны сатып алу һәм/яки ташу, төяү, җәю, килешү буенча эш өчен түләү);

- Тырыш бистәсендәге юлларны кардан чистарту (килешү буенча түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru һәм Тырыш бистәсе, Октябрьнең 70 еллыгы урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында урнаштырырга.

4. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык Л.Р.Әсәдуллина